РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ СТАРОИКШУРМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

422066, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Старая Икшурма, ул. Ленина, д.17
тел. (84362) 41-6-47

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИСКЕ ИКШЕРМӘ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422066, Татарстан Республикасы, Саба
районы,
Иске Икшермә авылы, Ленин урамы, 17 йорт
тел. (84362) 41-6-47

e-mail: sik.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
17.02.2023

КАРАР
№5

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советының 2021 елның 08 ноябрендә кабул ителгән №29 карары белән расланган Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Саба районы Прокуратурасының 09.02.2023 №02-08-02-2023/183-23-20920031 протесты һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 04.11.2022 №427-ФЗ Федераль законның «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 26.12.2008 елгы №294-ФЗ Федераль законның 14, 18 статьяларына (алга таба Закон) таянып, Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советының 08.11.2021 елгы №29 «Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» карары белән расланган “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында Нигезләмәгә” (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.4 пунктчасын түбәндәге эчтәлектәге дүртенче абзац белән тулыландырырга:

««Җитәкче, бүтән вазыйфаи зат яки юридик затның вәкаләтле вәкиле, индивидуаль эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле үтенече буенча дәүләт контроле

(күзәтчелеге) органының, муниципаль контроль органының вазыйфаи затлары тикшерелергә тиешле затларны административ регламентлар яисә контроль чараларын үткәрүне җайга сала торган башка норматив хокукый актлар һәм юридик зат, шәхси эшмәкәр эшчәнлеген башкарганда файдаланыла торган объектларда уздыру тәртибе белән таныштырырга тиеш.»;

1.2. Нигезләмәнең 4.6.1. пунктчасын түбәндәге эчтәлектәге өченче абзац белән тулыландырырга:

«Күчмә тикшерү үткәрелә башлаганчы, юридик затның бүтән вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, индивидуаль эшмәкәр, аның вәкаләтле вәкиле үтенече буенча, аларны административ регламент яисә башка норматив хокукый акт (шундый административ регламент яки башка норматив хокукый акт булганда) нигезләмәләре белән таныштыру, шулар нигезендә тикшерү үткәрелгәндә;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион "Интернет" челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/ikshurma адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Иске Икшермә авыл җирлеге башлыгы А.И.Биккинин